РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» ноябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3681

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның савым сыерлары һәм (яисә) таналар сатып алуга һәм аларны тотуга,үз хуҗалыгында 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны индивидуаль саву җайланмалары белән тәэмин итүгә бер һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарны азык (печән, салам, фураж, ашлык фуражы, премикслар) белән тәэмин итүгә киткән чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 7147 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы, «2023 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм кече хуҗалыкларны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 26 сентябрендәге 3507 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның савым сыерлары һәм (яисә) таналар сатып алуга һәм аларны тотуга,үз хуҗалыгында 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны индивидуаль саву җайланмалары белән тәэмин итүгә бер һәм аннан да күбрәк баш савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарны азык (печән, салам, фураж, ашлык фуражы, премикслар) белән тәэмин итүгә киткән чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 29

заказ № 1-851

ноябрендәге 7147 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 2.4 пунктындагы в) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) сатып алына торган савым сыерларына һәм (яисә) таналарга ветеринария белешмәләренең һәм таныклыкларның күчермәләре;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 29 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А. М. Каюмов